Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлеге составына керүче Шестая Речка авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАРЫ**

20 ноябрь 2019 ел № 2

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Шомбыт авыл җирлеге составына керүче Шестая Речка авылындагы гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде**:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт авыл җирлегенең Шестая Речка авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 1000 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;

2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:

- авыл җирлеге чикләрендә юлларны кышка карап тоту һәм ремонтлау;
- авыл җирлеге чикләрендә су белән тәэмин итү системасын тоту (су челтәрләрен ремонтлау, тирән насослар сатып алу););
- авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (пирс төзелеше, янгын сүндерү гидрантлары, янгын җиңсәләре, күрсәткечләр сатып алу);
- Шомбыт, Шестая Речка, Камский, Степановка торак пунктларында энергия саклаучы яктырткычлар һәм аларга комплектлау өлешләре сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау;
- авыл җирлеге чикләрендә чүп үләннәрен чабу.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбытавыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Шомбыт авылы, Совет урамы, 18 йорт;Шомбыт авылы, Завод урамы, 22 йорт; Шестая Речка авылы, Лесная урамы, 6 йорт, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Сергеев Н.Е.
Шомбыт авыл җирлеге башлыгы: Сергеев Н.Е.